ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.04.2020 г. Заинск №144

**"Социаль ярдәмнең аерым чаралары срогын озайту турында"**

Коронавирус йогышы таралу куркынычын минимальләштерү максатларында, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Җан башына уртача кереме 20,0 мең сумга кадәр булган гаиләләргә «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләренә йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 20 сентябрендәге 2078 номерлы карары белән билгеләнгән, түләүләр чоры 2020 елның 30 сентябренә тәмамлана торган, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә балаларны караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана түләвенең бер өлешенә өстәмә компенсация алучы гражданнарга социаль ярдәм чарасы буларак түләүләрне, кабат гариза бирмичә, 2020 елның 1 октябренә кадәр озайтырга.
2. Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтына урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.В. Чапковка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Хафизов**

Л.Р. Печина
3 27 42